**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «20» августыннан № 215

«2025 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл яшьләре» муниципаль программасын раслау турында

Яңа Чишмә муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы законы (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы редакциясендә), «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» Россия Федерациясе Президентының 2021 елның 04 февралендәге 68 номерлы Указы нигезендә, «Мәгариф» милли проектының «Социаль активлык», «Патриотик тәрбия» федераль проектларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән «2025 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл яшьләре» муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «20» августыннан
215 номерлы карары белән
расланды

«2025 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл яшьләре» муниципаль программасы

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2025-2028 елларга «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл яшьләре» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказчы (координатор) | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Программаның максаты һәм бурычлары | Яңа Чишмә муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру<br><br>Программа түбәндәгеләрне тормышка ашыру (ирешү) максатларында эшләнгән:<br><br>- «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон;<br><br>- «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы редакциядә);<br><br>- «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» РФ Президентының 2021елның 04 февралендәге 68 номерлы Указы;<br><br>- «Социаль активлык», «Мәгариф» милли проектының «Патриотик тәрбия» федераль проектлары.<br><br>Программаның бурычлары:<br><br>1. Укучы һәм студент яшьләрнең хезмәт активлыгының нәтиҗәле модельләрен үстерү өчен шартлар тудыру;<br><br>2. Авыл яшьләренең районның социаль-икътисади үсеше белән кызыксынуы һәм яшьләрнең бу процесста катнашырга әзерлеге.<br><br>3. Районда уңай демографик тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту;<br><br>4. Авыл яшьләренең шәһәргә күчүен кимүетү;<br><br>5. Авыл яшьләрен мәгълүмат белән тәэмин иту |

| | |
|---|---|
| | системасын булдыру.<br>6. Сәләтле балаларны һәм яшьләрне эзләү, аларга ярдәм итү, аларның интеллектуаль һәм иҗади потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру.<br>7. Яшьләр арасында тискәре-социаль күренешләрне профилактикалауның нәтиҗәле системасын формалаштыру һәм гамәлгә ашыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары | 2025 - 2028 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән финанслау күләме | Программаны финанслау Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар, җирле бюджетка билгеләнгән һәм билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелгән күләмнәрдә республика бюджеты чаралары хисабына башкарылачак:<br>2025 ел - 670,0 мең сум<br>2026 ел - 670,0 мең сум<br>2027 ел - 670,0 мең сум<br>2028 ел - 670,0 мең сум<br>Искәрмә: Күрсәтелгән чыганаклардан бүлеп бирелә торган акчалар күләме прогноз характерына ия һәм тиешле финанс елына бюджет проектын формалаштырганда, Программа чаралары исемлеген, ирешелгән нәтиҗәләр нигезендә аларны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын төгәлләштерүне исәпкә алып, билгеләнгән тәртиптә ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.<br>Агымдагы елда Программа чараларын финанслау булмаган очракта, алдагы елларда финанслау программа кысаларында, Программа чараларын үтәүгә каралган чаралар кысаларында башкарылачак. |
| Программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) еллар буенча һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Авылда социаль-икътисади үзгәртеп коруда яшьләрнең ролен арттыру.<br>Интеллектуаль, әхлакый һәм иҗади потенциалны арттыру, яшьләрнең милли үзаңын, гражданлык һәм патриотизмын үстерү.<br>Яшьләрне эш белән тәэмин итү.<br>Яшь буынның сәламәтлеген яхшырту.<br>Авылда җинаятьчелек, эчкечелек һәм наркомания дәрәҗәсе киму.<br>Авылда яшьләрнең торак-көнкүреш шартларын яхшырту.<br>Авыл яшьләренең эшлекле активлыгы һәм эшмәкәрлеге үсеше. |

## I. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемага характеристика

Хәзерге вакытта Яңа Чишмә муниципаль районында 12782 кеше яши. Авыл яшьләре (18 яшьтән 35 яшькә кадәр халык) 2575 кеше тәшкил итә, бу районның барлык авыл халкының 20,1% ын тәшкил итә.

Халык саны елдан-ел кими бара. Бу процессның төп сәбәпләренең берсе - 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшьләрнең шәһәргә миграция агымы артуы. Халыкның нәкъ менә шушы өлеше хезмәткә сәләтле һәм грамоталы булып тора, гаилә төзи, аңа туучы балаларның өч чирегә туры килә.

Авыл яшьләре арасында, барыннан да элек, хезмәткә сәләтле яшьтәге кешеләр саны кимүгә бәйле тискәре тенденцияләр күзәтелә.

Бүгенге көндә проект эшчәнлеген үстерү һәм авыл яшьләре арасында эшкуарлыкны үстерү мөһим бурыч булып тора. Ә бу аны социаль проектлауга, бизнес-планлаштыруга өйрәтүдән башка мөмкин түгел. Хәзер моны Интернет челтәре ярдәмендә, дистанцион укыту һәм вебинарлар программасын кулланып эшләргә мөмкин.

Социаль инновацион проектлау яшьләр мохитен үстерү факторы булып тора, шәхес барлыкка килүгә, аны социальләштерүгә, аның билгеле бер төр күнекмәләренә ия булуына һәм граждан җәмгыяте тормышында тулы кыйммәтле катнашуга ярдәм итә.

Социаль проектлау нигезләрен үзләштерүнең актуальлеге, беренчедән, әлеге технологиянең барлык һөнәрләр өчен дә киң кулланылыш өлкәсенә ия булуы белән аңлатыла. Икенчедән, социаль проектлау логикасы һәм технологиясен белү белгечләргә аналитик, оештыру-идарә итү һәм башка функцияләрне нәтиҗәлерәк башкарырга мөмкинлек бирәчәк, бигрәк тә дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә. Өченчедән, проект технологияләре белгечнең хезмәт базарында көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итә, социаль әһәмияткә ия проект эшләү һәм аны финанслауга гариза рәсмиләштерә белү - бу гамәлдәге учреждениеләр һәм оешмалар кысаларында да, аннан тыш та үзенә эш урыны булдыру мөмкинлеге.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программа түбәндәгеләрне тормышка ашыру (ирешү) максатларында эшләнгән:

- «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы редакциядә);
- «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм

Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» РФ Президентының 2021елның 04 февралендәге 68 номерлы Указы;

- «Социаль активлык», «Мәгариф» милли проектының «Патриотик тәрбия» федераль проектлары.

Программаның максаты - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш:

Авыл яшьләрен мәгълүмати тәэмин итү системасын булдыру авыл яшьләренә массакүләм мәгълүмат чаралары, мәгълүмат-полиграфия продукциясе, шулай ук IT-технологияләр куллану юлы белән махсус җайлаштырылган мәгълүмат җиткерергә мөмкинлек бирәчәк.

Авыл яшьләренең социаль активлыгын күтәрү өчен шартлар тудыру авыл яшьләре мәсьәләләре белән шөгыльләнүче яшьләр оешмалары төзүне, авыл яшьләренең иҗтимагый-сәяси активлыгын арттыруны, авыл яшьләрен социаль проектлауга өйрәтүне һәм яшьләрне авылны социаль үстерү программаларын гамәлгә ашыруга җәлеп итүне күздә тота.

Авыл яшьләренең икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру авыл яшьләрен бизнес-планлаштыру нигезләренә өйрәтү, авыл җирлегендә яшьләр мәшгульлегенә ярдәм итү һәм яшьләрне авылны икътисадый үстерү программаларын гамәлгә ашыруга җәлеп итү.

Авыл яшьләренең рухи, физик һәм иҗади үсешенә ярдәм итү интеллектуаль-иҗади һәм физкультура-савыктыру чараларын оештыруны һәм уздыруны, шулай ук яшүсмерләр һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга ярдәм итүне күздә тота.

Авыл яшьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын даими камилләштерү зарурлыгы аркасында Программаны гамәлгә ашыру 4 еллык чорга (2025 елдан 2028 елга кадәр) исәпләнгән һәм бер этапта гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыруны вакытыннан алда туктату күздә тотылмый.

## III. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны финанслау чыганагы - җирле бюджет акчалары. Дәүләт заказчысы-программаның координаторы итеп Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетын тора.

Программа үтәлешенә гомуми контрольне Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге гамәлгә ашыра.

Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге:

чираттагы финанс чаралары программасын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларны исәпкә алып, ел саен максатчан индикаторлар, программа чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнарны, программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм аны башкаручылар составын төгәлләштерә;

Җирле үзидарә органнарына түбәндәге функцияләрне башкарырга тәкъдим ителә:

«Авыл яшьләре» муниципаль программасы чараларын үз акчалары исәбеннән финанслауны тәэмин итәргә;

билгеләнгән тәртиптә муниципаль район җирлекләрендә авыл яшьләре мәсьәләләре белән шөгыльләнүче яшьләр иҗтимагый оешмалары булдыруга һәм аларга ярдәм итүгә булышлык күрсергә.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа озак вакытка исәпләнгән перспективага ия һәм Яңа Чишмә районы авыл яшьләрен этаплап колачлауны күздә тота. Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен җирле бюджет акчалары җәлеп ителә.

## V. Максатчан программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү.

Җирле бюджеттан җәлеп ителгән акчаларны куллану һәм Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге хисабына тәэмин ителәчәк:

бюджет акчаларын максатсыз файдалану мөмкинлеген төшереп калдыру;

бюджет акчаларын куллануның «үтә күренмәлелеге»;

Программа чараларын тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:

яшьләр иҗтимагый оешмаларында торучы авыл яшьләре өлешен арттырырга;

җирле үзидарә органнарында авыл яшьләре өлешен арттырырга;

авылны социаль һәм икътисадый үстерү программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл яшьләре санын арттырырга;

авыл яшьләрен социаль проектлаштыру һәм бизнес-планлаштыру нигезләренә өйрәтергә;

югары һөнәри белем алган авыл яшьләре санын арттырырга;

авыл яшьләре өчен интеллектуаль-иҗади чаралар оештырырга;

авыл яшьләре өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары оештырырга;

сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру программаларында катнашучы авыл яшьләре санын арттырырга.

Социаль проектлауга, бизнес-планлаштыруга өйрәтү авыл яшьләренә грант нигезендә конкурсларда катнашырга, үз эшен башлап җибәрергә, аз чыгымлы һәм нәтиҗәле программалар һәм проектлар кертергә мөмкинлек бирәчәк.

Программаны тормышка ашыру кысаларында Яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче программаны башкаручыларның торак, ташламалы кредитлар, белем алу турында махсус мәгълүматка ия конкрет белгечләре команда эше, социаль проектлау, бизнес-планлаштыру, электораль активлыкны арттыру кебек

гамәлдәге технологияләрдән файдаланып, Программа бурычларын үтәүгә ярдәм итәчәк, эшнең адреслы булуын, авылда төрле социаль, икътисади программаларны тормышка ашыруны тәэмин итәчәк.

Программа чараларын уңышлы үтәү түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

авыл яшьләренең районның социаль-икътисади үсеше белән кызыксынуы һәм аның бу процесста катнашырга әзерлеге;

авыл җирлегендә уңай демографик тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту;

авыл җирлегендә социаль киеренкелек дәрәҗәсен киметү;

авыл яшьләренең шәһәргә күчүен кимүетү;

дәүләт структураларына халыкның ышаныч дәрәҗәсен күтәрү;

авыл яшьләренең тормыш сыйфаты яхшырту.

# VI. Программа чаралары исемлеге

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Чараларның атамасы | Башкаручылар | Башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткече | | | | Финанслау күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Яңа Чишмә муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру | Яңа Чишмә муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру | Район чараларын интернет челтәрендә яктырту | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге. | 2025 - 2028 еллар | Үткәрелгән чаралар саны | 12 | 12 | 12 | 12 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | | Республика «КВН авыл лигасы»нда катнашу | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | 2025 - 2028 еллар | | 1 | 1 | 1 | 1 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Созвездие – Йолдызлык» республика ачык телевизион яшьләр фестиваленең муниципаль этабын оештыру һәм үткәрү, фестивальнең республика этапларында катнашу | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | 2025-2028 еллар | | 1 | 1 | 1 | 1 | 400,0 | 400,0 | 400,0 | 400,0 |
| | | «Безнең заман» «Наше время» эшләүче яшьләрнең телевизион иҗат фестивалендә катнашу | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | 2025-2028 еллар | | 1 | 1 | 1 | 1 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Студент көне» бәйрәм чарасын оештыру һәм үткәрү. | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге | 2025-2028 еллар | | 1 | 1 | 1 | 1 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| | | «Яшьләр көне» бәйрәм чарасын оештыру һәм үткәрү. | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | 2025-2028 еллар | | 1 | 1 | 1 | 1 | 80,0 | 80,0 | 80,0 | 80,0 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруның шартларын булдыру | Тәмәке тартуга, алкоголизмга, наркоманиягә каршы профилактик акцияләр оештыру һәм үткәрү | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге | 2025-2028 еллар | | 12 | 12 | 12 | 12 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруның шартларын булдыру | Эшләүче яшьләр арасында спорт ярышлары үткәрү, авыл яшьләре арасында Республика спартакиадаларында катнашу. | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге. | 2025-2028 еллар | | 9 | 10 | 10 | 11 | 150,00 | 150,0 | 150,0 | 150,0 |
| | | | Барлыгы: | | | | | | | 670,0 | 670,0 | 670,0 | 670,0 |